ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода, 422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы, 422591

Тел.: (84379) 3-11-18, факс: (84379) 3-11-18.

14.10.2023 № 3

На №______________ от________________

КАРАРЫ

Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Медведково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Медведково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешесеннән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы, дигән сорау буенча 2023 елның 14 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены протоколы төзелде:

- Медведково авылындагы контейнер мәйданчыгын урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 31 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 16 кеше. Җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 16 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Введенкский Бистәсе авыл җирлегенең Медведково авылында гражданнар җыенын узган дип таныргa, нәтиҗәләр - дөрес.

2. «2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Медведково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллап, түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә ризамы?

- Медведково авылында контейнер мәйданчыгын урнаштыру.

3. Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Медведково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д.В. Морозов